ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.03.2016 Казан ш. № 7-2/т

Керә торган тимер юлларда «Сәнәгать тимер юл транспортының Казан тармакара предприятиесе» акционерлык җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче транспорт хезмәтләренә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар билгеләү турында

«Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Керә торган тимер юлларда «Сәнәгать тимер юл транспортының Казан тармакара предприятиесе» акционерлык җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче транспорт хезмәтләренә максималь дәрәҗәдә чик тарифларны әлеге карар кушымтасына нигезләнеп билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының «Керә торган тимер юлларда «Сәнәгать тимер юл транспортының Казан тармакара предприятиесе» акционерлык җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче транспорт хезмәтләренә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар билгеләү турында 2014 елның 25 июлендәге 7-16/т санлы карарының 1 пункты үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазифасын башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча дәүләт комитетының
02.03.2016 № 7-2/т
карарына кушымта

## Керә торган тимер юлларда «Сәнәгать тимер юл транспортының Казан тармакара предприятиесе» акционерлык җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче транспорт хезмәтләренә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар

### I бүлек. Максималь дәрәҗәдә чик тарифлар

| № п/п | Күрсәтелүче хезмәт төре | Үлчәү берәмлеге | Максималь дәрәҗәдә чик тариф сумнарда (НДСтан тыш) |
|---|---|---|---|
| 1. | 3 км ераклыкка йөк ташу | 1 тонна | 80,50 |
| 2. | 3 км артык булган ераклыкка йөк ташу (1 тонна өчен өстәмә рәвештә һәр километрга) | 1 тонна | 26,98 |

### II бүлек. Башка шартлар

1. Сәнагый тимер юл транспорты предприятиесе тарафыннан башкарылган, әмма «Тарифлар» дип аталган 1 бүлектә каралмаган эшләргә һәм хезмәтләргә тарифлар Россия Федерациясе транспорт Министрлыгының 2001 елның 20 декабрендәге АН-104-р санлы боерыгы белән расланган сәнагый тимер юл транспорты тарафыннан башкарылган эшләргә һәм башка хезмәт күрсәтүләргә тарифларны һәм җыемнарны формалаштыру буенча Методик тәкъдимнәргә нигезләнеп, яклар килешүе белән билгеләнә.
2. Вагоннарның йөк күтәрүчәнлегеннән норматив файдаланып, йөк ташу һәм төяү-бушату эшләре өчен түләү, йөкнең факттагы авырлыгыннан чыгып, заказчыдан түләтелә.
3. Йөк ташуга түләү алу өчен ераклык, тулы санга кадәр түгәрәкләп, километрларда билгеләнә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге